КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 май г.Казань № 458

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 9 нчы; 2016 ел, 15 август, 565 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 648 нче; 2017 ел, 21 март, 171 нче; 2017 ел, 31 май, 327 нче; 2017 ел, 18 сентябрь, 680 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 784 нче; 2018 ел, 16 апрель, 252 нче; 2018 ел, 14 июнь, 474 нче; 2018 ел, 28 август, 723 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 885 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1304 нче; 2020 ел, 25 февраль, 142 нче; 2020 ел, 2 июнь, 455 нче; 2020 ел, 29 август, 756 нчы; 2020 ел, 2 октябрь, 898 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1188 нче; 2022 ел, 14 февраль, 126 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Дәүләт комитеты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән музейларга, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә, халык сәнгать һөнәрләренә (Россия Федерациясе законнарында каралган искәрмәләрдән тыш), республика һәм җирле милли-мәдәни автономияләргә, мәгариф учреждениеләрендә милли телләр һәм этномәдәни юнәлештәге башка предметларны өйрәнүгә, кинематографиягә ярдәм күрсәтү, шулай ук төрле диндәге дини берләшмәләрне үстерүгә һәм алар арасында үзара аңлашуны ныгытуга булышлык күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.03.02*);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01.03*);

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.14*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү (01.05.03*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

икътисадны мобилизацион әзерләү белән идарә итү (02.04*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү , инвестицион проектларны гамәлгә ашыруны комплекслы тәэмин итү функцияләрен тормышка ашырганда(01.10*);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру функцияләрен гамәлгә ашырганда (04.03.03*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10*).»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт комитеты түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

туризм өлкәсендә төп бурычларны һәм Татарстан Республикасында туризм үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгели;

Татарстан Республикасы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча туризм өлкәсендә стратегик планлаштыру документларын әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

туризм өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша;

Татарстан Республикасында туристлык индустриясен үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыра;

туристлар (экскурсантлар) (шул исәптән инвалидлар арасыннан булганнар) өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан туристлык ресурсларыннан һәм элемтә чараларыннан тоткарлыксыз файдалану мөмкинлегенә, шулай ук медицина ярдәменнән, хокукый һәм башка ашыгыч ярдәмнән файдалануга уңай шартлар тудыра һәм тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясендә туризм өлкәсендә навигация һәм ориентирны билгеләү системасын булдыру чараларын гамәлгә ашыра;

кунакханәләрне, тауда чаңгы шуу трассаларын, пляжларны классификацияләүне гамәлгә ашыручы аккредитацияләнгән оешмаларның алар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә планлаштырыла торган тиешле классификацияләрне гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләрен кабул итә;

Татарстан Республикасының туристлык продуктларын эчке һәм дөньякүләм туристлык базарларына чыгаруда булышлык күрсәтә;

Татарстан Республикасында туризм (шул исәптән социаль туризм, авыл туризмы, балалар туризмы һәм үзешчән туризм) үсешенең өстенлекле юнәлешләренә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыра;

гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар өчен мәдәни-танып белү максатлары белән экскурсияләр һәм сәяхәтләр оештыру чаралары комплексын гамәлгә ашыра;

туризм өлкәсендәге чараларны төбәк һәм муниципальара дәрәҗәдә оештыра һәм үткәрә;

туризм өлкәсендә хөкүмәтара килешүләрне гамәлгә ашыруда катнаша;

туризмны мәгълүмати тәэмин итүдә, Татарстан Республикасында туристлык мәгълүмат үзәкләрен төзүдә һәм аларның эшләвен тәэмин итүдә катнаша;

экскурсоводларны (гидларны) һәм гид-тәрҗемәчеләрне аттестацияләү өчен аттестация комиссиясен төзи, экскурсоводлар (гидлар) турында һәм гид-тәрҗемәчеләр турындагы мәгълүматны экскурсоводларның (гидларның) һәм гид-тәрҗемәчеләрнең бердәм федераль реестрына кертә;

экскурсоводның (гидның) яки гид-тәрҗемәченең күкрәк тәңгәлләштерү карточкасы формасын раслый;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы, экскурсоводлар (гидлар), гид-тәрҗемәчеләр һәм (яки) юлчыларга ярдәм итеп йөрүче инструкторлар хезмәтләре күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразлары проектларын һәм Татарстан Республикасы бюджеты проектына тәкъдимнәрне эшләүдә катнаша;

Дәүләт комитеты карамагындагы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр, шул исәптән Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын әзерли һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә билгеләнгән тәртиптә кертә;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча федераль программаларда Татарстан Республикасының катнашуы буенча тәкъдимнәр әзерли һәм аларны гамәлгә ашыруда катнаша;

туризмны һәм кунакчыллыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүне һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә туризмны үстерү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда җирле үзидарә органнарына методик ярдәм һәм булышлык күрсәтә;

туризм өлкәсе үсешенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләрен һәм аны үстерү чараларын куллану нәтиҗәлелеген анализлый, Татарстан Республикасында туризм өлкәсен үстерү фаразын әзерли;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм керә торган туризм өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә дәүләт ярдәме күрсәтә;

туризм һәм туристлык индустриясе өлкәсендә оешмаларның икътисадый, статистик, хокукый һәм башка мәгълүмат алуын тәэмин итә торган туризм өлкәсенә ярдәм итүнең мәгълүмат системасын формалаштыру эшен оештыра;

Россия һәм халыкара туристлык базарларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының туристлык мөмкинлекләрен һәм туристлык ресурсларын үстерү һәм популярлаштыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыра;

туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашырганда һәм уртак чаралар уздырганда дәүләт хакимиятенең федераль органнары белән хезмәттәшлек итә;

туризм һәм туристлык индустриясе өлкәсе оешмаларының төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлеген, шулай ук туризм һәм туристлык индустриясе өлкәсе мәнфәгатьләрен чагылдыра торган иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген үстерүгә булышлык күрсәтә;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча конференцияләр, фестивальләр, семинарлар, күргәзмәләр, конкурслар үткәрүне оештыра һәм Татарстан Республикасында һәм аннан читтә уздырыла торган башка чараларда катнаша;

Татарстан Республикасында туристларга яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыра;

туристлык индустриясе өлкәсендә кадрларның квалификациясен күтәрүдә методик ярдәм һәм булышлык күрсәтә;

үз компетенциясе чикләрендә шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

үз компетенциясе нигезендә башкарма хакимият федераль органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россиянең һәм чит илләрнең башка органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм башка гавами-хокукый характердагы актлар реестрын алып бара;

Дәүләт комитеты эшчәнлеге барышында барлыкка килгән архив документларын комплектлау, саклау, исәпкә алу һәм куллану эшләрен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра;

кунакханәләр белән – туристлык мөмкинлекләрен алга этәрү һәм объектларның хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту буенча, экскурсоводлар белән аларның квалификацияләрен күтәрү буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

Дәүләт комитеты карамагындагы өлкәгә карый торган өлештә мобилизация әзерлеге буенча оештыру һәм техник чаралар комплексын уздыруны тәэмин итә;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерә;

Дәүләт комитетын тотуга һәм аңа йөкләнгән функцияләрне тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче функцияләрен закон белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы халкының туристларга һәм туризм өлкәсенә лояльлеген арттыру чараларын оештыра һәм үткәрә;

Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча методик материаллар һәм тәкъдимнәр әзерли;

ел саен, 1 февральгә кадәр, коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына хисап тапшыра;

үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасын раслау турында» 2011 елның 19 августындагы 694 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр төзү, аларны үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү, аларны бетерү турында карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләр өчен учреждение уставында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрдә хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары бирелгән башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контролендә тотуны гамәлгә ашыра;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Дәүләт комитеты балансына тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән оператив идарә итүне гамәлгә ашыра;

Дәүләт комитеты ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча гражданнарга телдән һәм язмача хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм башка хокукый характердагы документлар төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый;

рекреацион билгеләнештәге җирләрне төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган территорияләр җирләренә кертү турында карар проектын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

үз компетенциясе чикләрендә төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган территорияләр җирләрен саклауны гамәлгә ашыра;

террорчылыкка каршы көрәш чараларын гамәлгә ашырганда өйрәнүләр үткәрүдә катнаша;

Дәүләт комитетына беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланганлыгына карата таләпләрнең үтәлешен оештыра һәм тәэмин итә;

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләүне һәм бу абзацта күрсәтелгән коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләр билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне гамәлгә ашыра.»;

4.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туризм өлкәсендә һөнәри белем, өстәмә белем бирүне һәм һөнәри укытуны оештыруда катнашырга;».

2. Бу карар (1 пунктның 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә торган кырык дүртенче – кырык алтынчы, сиксән җиденче һәм сиксән сигезенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин